**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **25.10.2022**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Урсай авыл җирлеге составына керүче
Урсай авылында 2022 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Урсай авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2023 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнүчеләрнең гаилә әгъзаларыннан тыш, бер тапкыр бирелә торган түләүне киметергә 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертергә һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:
-Урсай авылы урамнарын яктырту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар, урам утларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү)буенча хезмәт күрсәтү;
-Урсай авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (тракторчыга механикалаштырылган кар чистарту хезмәтләре өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәте);
- Урсай авылында халыкны су белән тәэмин итүне оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, су чыганакларының ТСО белән тәэмин итү, ЗСО проектларын әзерләү буенча хезмәтләр өчен түләү, эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ ясау) ;
- Урсай авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (»Сабантуй«, " Халыкара өлкәннәр көне»нә бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу);
-җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, үләнне механикалаштырылган чабу буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Урсай авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту: Җәлил, Горький, Ленин, Совет, төзүчеләр, Киров, Куйбышев, Кошевой, Тукай, Гастелло, Үзәк урамның 2-56 һәм 81-104 йортлар арасындагы вак таш җәелгән юлларны профильләштерү; Үзәк уерамның 81 нче йорт тыкрыгына юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм/яки ташу, вак таш салу контракт буенча эш өчен түләү).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:
-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үрсай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Урсай авыл җирлеге башлыгы З.Х.Рахимьянова